| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>Сарман авыл жирлеге** | **Сармановское сельское поселение<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 октябрь 2025 ел № 19

Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.12.2024 №15 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының г, д пунктчасы нигезендә Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.12.2024 №15 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::
2 бүлек 2.5 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк "сүзләрен" мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк " сүзләренә алмаштырырга;
2.Әлеге мәгълүматны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.
3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Шәрипова